Том 1, выпуск 7

Май/ 2025

**МБМБУ «Яңа Кенәр балалар бакчасы»**

# *Чишмә башы*

*Ананың балага биргән иң зур бүләге-тел.*

## Без– табигать баласы.



Соңгы елларда табигатьне саклау,балаларга экологик тәрбия бирү-иң зур проблемаларның берсе булып тора.Чөнки сулаган һавабыз,эчкән суыбыз пычранып бетә,табигать,бөтен тереклек зур куркыныч астында калды . Экологик проблемалар педагогларны да битараф калдырмича,балаларга экология тәрбиясе бирү бурычын куя .Моны кече яшьтән башларга кирәк . Безнең максат –мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган як табигатенең үсемлек һәм хайваннар дөнясы белән таныштыру,аларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.Табигатьне күзәтү,аны өйрәнү,сакларга омтылубалаларның рухи дөнясын баета,уйларга өйрәтә. Бакчабызда һәр төркемдә экологик почмак булдырдык. Шау чәчәктә утырган гөлләрнең матурлыгына сокланалар.Кышын тәрәзә төпләрендә суганың үстерү,аның үсешен күзәтү балалар өчен бик кызык .Ел әйләнәсе кошларны күзәтәбез.”Кошларга җимлек “акциясе оештырабыз.Кошларны даими тукландырып торабыз.Ә матур язлар җиткәч “Кошлар көне “үткәрәбез Сыерчык ояларына конкурс була .Сыерчык ояларын агач башларына урнаштырып ,сыерчыкларның кайтуын көтәбез.”Табигатькә – агач бүләк ит ! акцияләрендә катнашабыз .Әти –әниләр балалар белән берлектә агач куаклар утырталар .Аларны тәрбияләп яшәрүен көтәбез .Кече яшьтән үк балаларның табигатьне сакларга ,аны яратып үсүләрен телибез. Без- табигать баласы

ЭКОЯЗ - 2025 1 апрельдән Татарстанда традицион «Экояз»республика конкурсы старт алды. Узган елдагы кебек үк, конкурс экологик квест формасында уздырыла, аның биремнәре атна саен үзгәрәчәк. Быел " ЭКОяз " Ватанны саклаучылар елына һәм Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына багышланган. Бу чараларда балалар да ,әти-әниләр дә бик теләп катнашалар.

## *Туган телем сагында*




Балалар бакчасында балаларның киләчәгенә юл салына.Баланы кече яшьтән үк туган телен яратырга, дөрес, матур,аңлаешлы итеп сөйләшергә өйрәтү мөһим.Бүгенге көндә балаларның сөйләм теле тиешле дәрәҗәдә түгел дип саныйм, чөнки алар сөйләм вакытында сүзләрне йота, русча сүзләр кулланып сөйләшә, күп авазларны әйтә алмый. Гаиләдә дә бала белән аралашу җитми. Бу максаттан, бакчабызда санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар , татар халык уеннары ярдәмгә килә.Уеннар вакытында балаларның сөйләм теле формалаша. Без балалар белән “ Кәрия-Зәкәрия” , Чума үрдәк, чума каз” , “ Утыр, утыр Мәликә” , “ Гөлбану” , “ Түбәтәй” уеннарын яратып уйныйбыз.

Әгәр баланың сөйләмендә тайпылышлар була икән, андыйлар гадәттә,үз эченә бикләнүчән була. Хәтта бу кимчелекләр баланың акыл үсешенә зыян салырга, психикасы бозылырга мөмкин. Укуда да артта калуы ихтимал. Сабыйның сөйләмендәге кимчелекләргә вактында игътибар итәргә кирәк. Ул кимчелекләрне төзәтү өстендә 3-4 яшьтән шөгыльләнә башламасаң, вакыт үткән саен кыенрак булачак.Кайбер авазларны әйтә алмау,бозып әйтү, басымнарны ялгыштыру, авазларны йоту, иҗекләрне бутау – болар барысы да балалар сөйләмендәге төп кимчелекләр булып тора. Бала белән өйдә дә шөгыльләнергә кирәк.



## *Әйдәгез, уйныйбыз!*

“**Балалар белән уйнар өчен төрле-төрле уеннар:**

**Аю-бүре**

Бу күмәк уен җәй көне тышта, җае туры килгәндә, әрәмәлек буйларында уйнала.
Балаларның берсе аю яки бүре булып берәр җирдә посып тора. Башкалары урманга «җиләк җыярга» китәләр. Берәү аларга каршы очрап сораша:
— Дуслар, кая барасыз?
— Кара урманга барабыз.
— Кара урманда нишлисез?
— Кура җиләк җыябыз.
— Җиләк белән нишлисез?
— Җиләктән как коябыз.
— Бүре килсә нишлисез?
— Урман буйлап чабабыз.
Аннан соң барысы да күмәкләп җырлыйлар:
Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә;
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.
Бүре яшеренгән җиреннән сикереп чыга да аларны куа башлый. Кемне тотса, шул бүре була.
Уен йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерүгә ярдәм итә.

**Кап та коп**

Берничә бала бер түгәрәк булып утыралар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларын бергәләп күтәреп-төшереп шуны әйтәләр:
Без-без, без идек,
Без унике кыз идек;
Базга төштек бал ашадык,
Келәткә кердек май ашадык;
Өйгә мендек өйрә эчтек,
Коега төштек су эчтек;
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык,
Кап та коп,
Авызыңны ач та йом! —
диләр дә барысы да берьюлы авызларын йомалар.
Моннан соң уенчылар берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш.



· Телефон: 8(84366)91-1-32
422031, Республика Татарстан, Арский район, с.Новый Кинер, улица Пионерская, дом 10

*Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Новокинерский детский сад» Арского муниципального района Республики Татарстан функционирует с 30 декабря 2003 года.*

**График работы МБДОУ «Новокинерский детский сад":**

Понедельник - с 7.00 до 17.30

Вторник – с 7.00 до 17.30

Среда - с 7.00 до17.30

Четверг - с 7.00 до 17.30

Пятница - с 7.00 до17.30

[ адрес официального сайта ДОУ: https://edu.tatar.ru/arsk/n-kiner/dou ]